ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЧУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӨЧЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2025 Түбән Көчек авылы № 15

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге торак пунктларын янгыннан саклауны ныгыту максатларында чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулын билгеләү турында»гы 2021 елның 17 маенда кабул ителгән 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 16.09.2025 елның 16 сентябрендә кабул ителгән № 1479 карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 2025 елның 3февралендә кабул ителгән № 90 карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге торак пунктларын янгыннан саклауны ныгыту максатларында чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулын билгеләү турында» 2021ның 17 маенда кабул ителгән № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге торак пунктларын янгыннан саклауны ныгыту максатларында чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм эшләнмәләрне яндыру урыны һәм ысулы» кушымтасының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак пунктларның гомуми файдаланудагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан шәхси йорт биләмәләре территорияләрендә ризык әзерләү өчен ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә яндыру тыела.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының  Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлләре  2025елның 1сентябреннән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе Ә.Р.Төхвәтуллина